Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

№ 10 26.10. 2020 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге башкарма комитетының
«Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге
территориясендә терекөмешле лампаларны кулланучыларда
эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю
һәм урнаштыру урыннары турында» 23.09.2016 ел, №8
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контрольдә тоту чараларын үткәргәндә үтәлергә тиешле мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган, Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларының һәм аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында, федераль башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларын юкка чыгару хакында» 11.07.2020 ел, №1036 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны кулланучыларда эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары турында» 23.09.2016 ел, № 8 карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:
   1.1. Карарның 1.3. пунктын 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http:/pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге адрес буенча: http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырылырга .
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Емелькино авыл җирлеге башлыгы: Н.И.Михайлова.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕМЕЛЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ